КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 август г.Казань № 741

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетында каралган федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчаларны баш бүлүче итеп Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгын билгеләргә:

муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидия рәвешендә һәм дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру өчен җаваплылык йөкләргә:

авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту буенча;

торак урыны наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзелеше буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтү буенча;

авыл территорияләрен төзекләндерү буенча чараларны тормышка ашыру буенча;

авыл территорияләрендә компактлы торак төзелеше өчен мәйданчыкларны комплекслы төзекләндерү проектларын гамәлгә ашыру буенча;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидия рәвешендә, һәм ның квалификацияле белгечләр белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларын гамәлгә ашыру өчен җаваплылык йөкләргә.»;

8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында торак шартларын яхшырту чараларында катнашучылар исемлекләрен формалаштыру һәм раслау һәм авыл территорияләрендә торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләү бирү турында таныклыклар бирү тәртибе»;

Торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак алучы гражданнар исемлекләрен формалаштыру һәм раслау тәртибе;

Квалификацияле белгечләр белән тәэмин итүгә ярдәм итү өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү кагыйдәләре.»;

Әлеге карар белән расланган Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидияләр бирү өчен муниципаль берәмлекләрне сайлап алу критерие - социаль түләүләрне файдаланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнар исемлекләре булу, «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында торак шартларын яхшырту чараларында катнашучылар исемлекләрен формалаштыру һәм раслау тәртибенә 3 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карары (алга таба – исемлекләр) белән расланган авыл территорияләрендә торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләү бирү турында таныклыклар бирү.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Чираттагы финанс елына ($V_i$) i-муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган субсидияләр күләме чираттагы финанс елына Министрлык тарафыннан расланган социаль түләүләр алучыларның төгәлләштерелгән җыелма исемлегенә кертелгән муниципаль берәмлек алучыларына исәпләнгән федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән социаль түләүләр күләме буларак түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_i = \sum_{i=1}^{n} (S \times C_{кв.м.}) \times 0{,}7 + \sum_{i=1}^{z} ((S \times C_{кв.м.}) \times (100\% - G)) \times 99\%,$$

монда:

n – чираттагы финанс елына тәгаенләнгән җыелма исемлеккә кертелгән муниципаль район буенча социаль түләүләр алучылар саны, яңа төзелешкә яки торак сатып алуга социаль түләүләр бирелгән очракта;

z – чираттагы финанс елына тәгаенләнгән җыелма исемлеккә кертелгән муниципаль район буенча социаль түләүләр алучылар саны, элек башланган торак йортны төзеп бетерү өчен социаль түләү бирелгән очракта;

S - чираттагы финанс елына тәгаенләнгән җыелма исемлеккә кертелгән, Нигезләмәнең 15 пункты нигезендә гражданга һәм аның гаилә әгъзаларына исәпләнгән торак урыны гомуми мәйданы күләме;

$С_{кв.м.}$– чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган торакның бер квадрат метр гомуми мәйданының бәясе. Төзелгән (сатып алынган) торакның гомуми мәйданының факттагы бәясе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясеннән кимрәк булса, күрсәтелә торган бәя бер квадрат метр гомуми торак мәйданының факттагы бәясенә тигез итеп кабул ителә;

Г – торак йортны элек башланган торак төзелешен тәмамлау өчен социаль түләү биргән очракта торак йортның әзерлеге проценты.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. План чорына ($V_{iплан}$) i-муниципаль берәмлек бюджетына субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{iплан} = S_{мин} + (V_о - \sum_{i=1}^{n} S_{мин}) \times \frac{ДКУ_i \times \frac{Y_i}{100}}{\sum_{i=1}^{n} (ДКУ_i \times \frac{Y_i}{100})},$$

монда:

$V_о$ – әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын финанслашу өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр исәбеннән план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме;

$S_{мин}$ – i-муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган субсидиянең минималь күләме 1 096 200 сум.;

n - исемлек биргән муниципаль берәмлекләр саны;

$ДКУ_i$ – чираттагы финанс елына i-муниципаль берәмлек буенча җыелма исемлеккә кертелгән чараларда катнашучылар саны түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$ДКУ_i = \frac{\left(\frac{K_{оi}}{K_о} + \frac{K_{апкi}}{K_{оапк}}\right)}{2},$$

монда:

$K_{оi}$ - агросәнәгать комплексында, авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда һәм социаль өлкәдә эшләүче, чираттагы финанс елына i-муниципаль берәмлектә җыелма исемлеккә кертелгән чараларда катнашучылар саны;

$K_о$ – агросәнәгать комплексында, авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда һәм социаль өлкәдә эшләүче,

барлык муниципаль берәмлекләр буенча чираттагы финанс елына җыелма исемлеккә кертелгән чараларда катнашучыларның гомуми саны;

$К_{апкi}$ Кoi - агросәнәгать комплексында, авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда эшләүче, чираттагы финанс елына i-муниципаль берәмлектә җыелма исемлеккә кертелгән чараларда катнашучылар саны;

$К_{оапк}$ – агросәнәгать комплексында, авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда эшләүче, барлык муниципаль берәмлекләр буенча чираттагы финанс елына җыелма исемлеккә кертелгән чараларда катнашучыларның гомуми саны;

$Y_i$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен раслана һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 20 сентябрь, 851 нче карары белән расланган Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 13 пункты нигезендә билгеләнә торган Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек чыгым йөкләмәләрен финанслауның иң чик дәрәҗәсе;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Субсидияләрдән файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү хисап чорында субсидияләрне куллану нәтиҗәсенең факттагы ирешелгән күрсәткечләрен, Килешүдә каралган субсидияләрдән файдалану нәтиҗәләренең мәгънәләре белән чагыштыру юлы белән башкарыла.»;

әлеге Кагыйдәләргә кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Торак урынын наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзелеше буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидияләр бирү өчен муниципаль берәмлекләрне сайлап алу критерие – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карары белән расланган Торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак алучы гражданнар исемлекләрен формалаштыру һәм раслау тәртибенә 3 нче кушымта нигезендә һәм (яисә) эш бирүче тарафыннан расланган һәм җирле үзидарә органы белән килештерелгән, агымдагы финанс елында эш бирүче тарафыннан торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак алучы гражданнар җәлеп ителәчәк яңа штат берәмлекләре исемлеген төзү планлаштырылган торак урынын наем шартнамәсе буенча чараларда катнашучылар исемлекләре (алга таба - исемлекләр).

Эш бирүче дигәндә граждан белән хезмәт мөнәсәбәтләренә кергән юридик зат (шул исәптән шәхси эшмәкәр) аңлана.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Чираттагы финанс елына ($V_i$) муниципаль берәмлек бюджетына субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_i = \sum_{i=1}^{n} (R \times C) \times 0{,}8,$$

монда:

n – чираттагы финанс елына төгәлләштерелгән җыелма исемлеккә кертелгән муниципаль район буенча торак урыннары наемы шартнамәләре буенча торак алучы граждannар саны;

R – чираттагы финанс елына билгеләнгән җыелма исемлеккә кертелгән Нигезләмәнең 6 пункты нигезендә гражданга һәм аның гаиләсенең барлык әгъзаларына исәпләнгән торак урыны гомуми мәйданы күләме һәм (яисә) штат берәмлекләре;

C – чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган торакның бер квадрат метр гомуми мәйданының бәясе.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. «7. План чорына ($V_i$план) i-муниципаль берәмлек бюджетына субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{iплан} = V_o \times \frac{S_i \times \frac{Y_i}{100}}{\sum_{i=1}^{n}(S_i \times \frac{Y_i}{100})},$$

монда:

$V_o$ Vo – әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын финанслашу өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр исәбеннән план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме;

$S_i$ – әлеге карар белән расланган Торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак алучы гражданнар исемлекләрен формалаштыру һәм раслау тәртибенең 13 пунктында күрсәтелгән җыелма исемлек нигезендә i-муниципаль берәмлегенә субсидияләр күләме:

$$S_i = P_i \times 0{,}8,$$

монда:

$P_i$ – әлеге карар белән расланган Торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак алучы гражданнар исемлекләрен формалаштыру һәм раслау тәртибенең 13 пунктында күрсәтелгән җыелма исемлек нигезендә i-муниципаль берәмлеге буенча чараларда катнашучыларга торак төзелешенең исәп-хисап бәясе;

n - исемлек биргән муниципаль берәмлекләр саны;

$Y_i$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен раслана һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 20 сентябрь, 851 нче карары белән расланган Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан

субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 13 пункты нигезендә билгеләнә торган Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек чыгым йөкләмәләрен финанслауның иң чик дәрәҗәсе;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Субсидияләрдән файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү хисап чорында субсидияләрне куллану нәтиҗәсенең факттагы ирешелгән күрсәткечләрен, Килешүдә каралган субсидияләрдән файдалану нәтиҗәләренең мәгънәләре белән чагыштыру юлы белән башкарыла.»;

әлеге Кагыйдәләргә кушымтаны үз көчен югалткан дип таныргa;

Әлеге карар белән расланган Авыл территорияләрен яхшырту буенча чараларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидияләр авыл территорияләрен төзекләндерү буенча иҗтимагый әһәмиятле проектларны (алга таба – проект) тормышка ашыру өчен түбәндәге юнәлешләр буенча бирелә:

а) сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен ял итү зоналарын, спорт һәм балалар өчен уен мәйданчыклары, адаптив физик культура һәм адаптив спорт белән шөгыльләнү өчен мәйданчыклар булдыру һәм төзекләндерү;

б) территорияләрне, биналарны, корылмаларны, шул исәптән энергия саклау технологияләрен кулланып, архитектур яктыртуны да кертеп, яктыртуны оештыру;

в) җәяүлеләр коммуникацияләрен, шул исәптән тротуарларны, аллеяларны, велосипед юлларын, сукмакларны оештыру;

г) автомобиль һәм велосипед парклары урыннарын булдыру һәм төзекләндерү;

д) урам-юл челтәрен һәм ишегалды юлларын ремонтлау-торгызу эшләре;

е) муниципаль милектә булган биналарның (административ биналарның, социаль өлкә объектларының, инфраструктура объектларының һ. б.) фасадларын (тышкы кыяфәтен) формалаштыруны оештыру, шулай ук җәмәгать территорияләренә якын-тирәдәге коймаларны, газон һәм тротуар киртәләрен урнаштыру (төзекләндерү);

ж) инвалидларның һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәренең тоткарлыксыз хәрәкәтен тәэмин итү максатларында территорияне төзекләндерү;

з) яңгыр суларын агызуны оештыру;

и) җәмәгать коеларын һәм су җыю колонкаларын төзекләндерү;

к) каты коммуналь калдыкларны җыю мәйданчыкларын төзекләндерү;

л) табигый ландшафтларны һәм тарихи-мәдәни һәйкәлләрне саклау һәм торгызу.

Төзекләндерү элементлары һәм проектларга кертелә торган эш төрләре Министрлык боерыгы белән билгеләнә.»;

күрсәтелгән карарга «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында торак шартларын яхшырту чараларында катнашучылар исемлекләрен формалаштыру һәм раслау һәм авыл территорияләрендә торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләү бирү турында таныклыклар бирү тәртибе, торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак алучы

гражданнар исемлекләрен формалаштыру һәм раслау тәртибе, квалификацияле белгечләр белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү кагыйдәләрен өстәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин